ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2018 г. Заинск №1589

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 26 декабрендәге 2987 номерлы «2017-2019 елларга Зәй муниципаль районының Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү һәм үстерү турында муниципаль программасын раслау » карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга, «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты:

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2019 елларга Зәй муниципаль районының Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү һәм үстерү турында муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 2987 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктның 3нче булегендә “Программа чараларының исемлеген һәм тасвирламасын» түбәндәге чаралар белән тулыландырырга:

- Социаль эшмәкәрләр өчен мәгълүмати-методик ярдәм.

1.2. «2017-2019 елларга Зәй муниципаль районының Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү һәм үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру буенча төп чаралар исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлек буенча урынбасары П. А. Байрашевка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Юрист
А.Н. Симашева